ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**«04» февраль 2025 ел** **№ 92**

**Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм 2025 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен билгеләү турында**

Россия Федерациясе Торак кодексы, “Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында” 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күрсәткечләрен билгеләү Методикасы, Россия Төзелеш Министрлыгының “Россия Федерациясе буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метры һәм Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе нормативын билгеләү методикасын раслау турында” 2024 елының 28 мартындагы 215/пр номерлы боерыгы, Арча муниципаль районы Башкарма комитетының “Социаль наем һәм Дәүләт торак программалары буенча гражданнарга торак исәпкә куелганда һәм бирелгәндә торак мәйданы нормативлары турында” 2021 елның 4 маендагы 311нче карары нигезендә, Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елга гражданнарны аз керемлеләр дип тану турында карар кабул итү өчен түбәндәге чик күрсәткечләрне билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чиге:

1.1.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен – 1064166,00 сум;

1.1.2. Ике кешедән торган гаилә өчен – 2128332,00 сум;

1.1.3. Өч кешедән торган гаилә өчен – 3192498,00 сум;

1.1.4. Дүрт кешедән торган гаилә өчен – 4256664,00 сум;

1.1.5. Биш кешедән торган гаилә өчен –5320831,00 сум;

1.1.6. Алты кешедән торган гаилә өчен – 6384997,00 сум;

1.1.7. Җиде кешедән торган гаилә өчен – 7449163,00 сум;

1.1.8. Сигез кешедән торган гаилә өчен – 8513329,00 сум;

1.1.9. Тугыз кешедән торган гаилә өчен – 9577495,00 сум;

1.1.10. Ун кешедән торган гаилә өчен – 10641661,00 сум.

1.2. Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең иң чик күрсәткеченең күләме исәп-хисап буенча (1 нче кушымта) түбәндәгене тәшкил итә: гаиләнең һәр әгъзасына 22294,00 сум.

2. Арча муниципаль районы муниципаль берәмлекләренә торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәпкә куелганда әлеге карарның 1.1. һәм 1.2. пунктчаларында күрсәтелгән чик күрсәткечләрдән файдаланырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http:arsk.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы башкарма комитеты Аппаратының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы И. М. Хәсәновка йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.М.Гатиятов

*Арча муниципаль районы*
*башкарма комитеты*
*карарына Кушымта*
*04 02 2025 ел № 92*

**Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм 2025 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен билгеләү**
**МЕТОДИКАСЫ**

**1. Социаль наем шартнамәләре буенча муниципаль торак фондыннан торак урыннар бирү нормасы буенча торак урыннар сатып алуның базар хакының исәп-хисап күрсәткече (алга таба - исәп-хисап күрсәткече) түбәндәге формула буенча исәпләнә:**

**СЖ = НП х РС х РЦ**, монда

СЖ - социаль наем шартнамәсе буенча торак урын бирү нормасы буенча торак урын сатып алуның базар хакының исәп-хисап күрсәткече;

НП - әлеге муниципаль берәмлектә гаиләнең бер әгъзасына торак урын бирү нормасы;

РС - гаилә әгъзалары саны;

РЦ - торак урын мәйданының бер квадрат метры әлеге муниципаль берәмлекнең уртача шартларына һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин ителешенә туры килә торган уртача исәп-хисап базар бәясе, ул Татарстан Республикасында торак урын сатып алуга түләүсез субсидияләрне исәпләү өчен тиешле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән гомуми мәйданның бер квадрат метрының уртача базар бәясеннән артмый.

а) ялгыз яшәүче граждан өчен:

СЖ = 59120.34 х 18 = 1064166,00 сум

б) ике кешелек гаиләгә:

СЖ = 59120.34 х18 х 2 = 2128332,00 сум

в) өч кешелек гаиләгә:

СЖ = 59120.34 х 18 х 3 = 3192498,00 сум

г) дүрт кешелек гаиләгә:

СЖ = 59120.34 х 18 х 4 = 4256664,00 сум

д) биш кешелек гаиләгә:

СЖ = 59120.34 х 18 х 5 = 5320831,00 сум

е) алты кешелек гаиләгә:

СЖ = 59120.34 х 18 х 6 = 6384997,00 сум

ж) җиде кешелек гаиләгә:

СЖ = 59120.34 х 18 х 7 = 7449163,00 сум

3) сигез кешелек гаиләгә:

СЖ = 59120.34 х 18 х 8 = 8513329,00 сум

и) тугыз кешелек гаиләгә:

СЖ = 59120.34 х 18 х 9 = 9577495,00 сум

к) ун кешелек гаиләгә:

СЖ = 59120.34 х 18 х 10 = 10641661,00 сум

**2. Гражданның гаиләсендә һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләменең чик күрсәткече:**

**ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1 - (1 + ПС) $^{-КП}$ ) / (0,3 х РС)**, монда

ПД - һәр гаилә әгъзасына туры килә торган һәм СЖ исәп-хисап хакы буенча торак урын сатып алу өчен агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле уртача айлык җыелма керемнең иң чик күрсәткече;

СЖ - социаль наем шартнамәсе буенча торак урын бирү нормасы буенча торак урын сатып алуның базар хакының исәп-хисап күрсәткече;

ПС - кредит буенча бер айга процент ставкасы (унарлы вакланма), елга 7 %, ягъни айга 7/100/12 = айга 0,058 (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 22 августындагы "Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында" 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру буенча алга таба чаралар хакында" 366 номерлы карары нигезендә)

КП - кредитның бөтен срогы өчен кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны);

РС - гаилә әгъзалары саны;

0,7 - кредит суммасы һәм фатир бәясе нисбәте;

0,3 - кредит буенча түләүнең гаиләнең айлык җыелма кереме белән нисбәте.

2025 елның 23 гыйнварындагы "2025 елның 1 яртыеллыгында торак базарына анализ" 22нче номерлы "Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлеге" коммерцияле булмаган партнерлык хаты нигезендә, Арча муниципаль районында 1 квадрат урынның уртача бәясе 59120.34 сум тәшкил итә.

**Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күрсәткечен исәпләп чыгару**

Табл. №1

| НП - торак урын нормасы (кв. м) | СЖ - торак урын сатып алуның базар бәясе (СЖ = РС х РЦ х НП) (сум.) | РС - гаилә әгъзалары саны (кеше) | РЦ - торак урынның 1 кв. м базар бәясе (сум) | ПС - бер айга кредит буенча процент ставкасы, % | КП - кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (ай) | Кредит суммасы һәм фатир бәясе нисбәте | Кредит буенча түләүнең тулаем айлык керем белән нисбәте | ПД - керемнең чик кыйммәте (сум) (гаиләгә) | Керемнең чик әһәмияте (сум) (кешегә) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | |
| | 1064166,00 | | 59120,34 | 7/100/12 =0,0058 | 180 | 0,7 | 0,3 | | |
| 18 | 1064166,00 | 1 | 59120,34 | 0,0058 | 180 | 0,7 | 0,3 | 22294,00 | 22294,00 |
| 36 | 2128332,00 | 2 | 59120,34 | 0,0058 | 180 | 0,7 | 0,6 | 44585,00 | 22294,00 |
| 54 | 3192498,00 | 3 | 59120,34 | 0,0058 | 180 | 0,7 | 0,9 | 66876,00 | 22294,00 |
| 72 | 4256664,00 | 4 | 59120,34 | 0,0058 | 180 | 0,7 | 1,2 | 89167,00 | 22294,00 |
| 90 | 5320831,00 | 5 | 59120,34 | 0,0058 | 180 | 0,7 | 1,5 | 111458,00 | 22294,00 |
| 108 | 6384997,00 | 6 | 59120,34 | 0,0058 | 180 | 0,7 | 1,8 | 133749,00 | 22294,00 |
| 126 | 7449163,00 | 7 | 59120,34 | 0,0058 | 180 | 0,7 | 2,1 | 156040,00 | 22294,00 |
| 144 | 8513329,00 | 8 | 59120,34 | 0,0058 | 180 | 0,7 | 2,4 | 178331,00 | 22294,00 |
| 162 | 9577495,00 | 9 | 59120,34 | 0,0058 | 180 | 0,7 | 2,7 | 200622,00 | 22294,00 |
| 180 | 10641661,00 | 10 | 59120,34 | 0,0058 | 180 | 0,7 | 3,0 | 222913,00 | 22294,00 |